ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристлар, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

24.04.2019 — с. Печищи — № 7

**Хөкем ителгәннәргә төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаларны үтәү урыннарын билгеләү турында**

Югары Ослан районы прокурорының 2010 елның 15 апреленнән № 02-04-02 протестын карап чыкканнан соң, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 ст. 1 ө., 50 ст. 1 ө. һәм Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 25 ст. 1 ө., 39 ст. 1 ө. нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге территориясендә яшәүче хөкем ителгәннәргә төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаларны үтәү өчен,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге территориясендә яшәүче төзәтү эшләренә хөкем ителгәннәрнең җәзаларны үтәү өчен предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге территориясендә яшәүче мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәрнең исемлеген җәзаларны үтәү өчен предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр расларга (№2 нче кушымта).
3. Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетының "Төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгән Җәзаларны үтәү урыннарын билгеләү турында" 15.01.2019 ел № 4 карары үз көчен югалткан дип санарга.
4. ТР буенча Россия ҖҮФХИ Кама Тамагы ФКУ УИИ муниципальара филиалына предприятие, оешма һәм учреждениеләр исемлекләрен килештерү өчен җибәрергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Печищи авыл җирлеге Башлыгы** **Л.В.Яковлев**

**«Килештерелгән»**
**Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең ТР буенча Россия ҖҮФХИ Кама Тамагы ФКУ УИИ муниципальара филиалы башлыгы**

**_________________**
**«____» _________________ 2019 ел**

Печищи авыл җирлеге

Башкарма комитетының

24.04.2019 ел № 7 карарына

1нче кушымта.

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге территориясендә яшәүче төзәтү эшләренә хөкем ителгәннәрнең җәзаларны үтәү өчен оешма, предприятие һәм учреждениеләр**
**ИСЕМЛЕГЕ**

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- Печищи «МУП»;
- «Татарстан бөртекле технологияләре» АҖ;
- «Сетевая компания» ААҖ филиалы Буа электр челтәрләренең Югары Ослан участогы.

**Печищи авыл җирлеге Башлыгы Л.В.Яковлев**

**«Килештерелгән»**
**Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең ТР буенча Россия ҖҮФХИ Кама Тамагы ФКУ УИИ муниципальара филиалы башлыгы**

**_______________**
**«____» ________________ 2019 ел**

Печищи авыл җирлеге

Башкарма комитетының

24.04.2019 ел № 7 карарына

2нче кушымта.

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге территориясендә яшәүче мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәрнең җәзаларны үтәү өчен оешмалар, предприятиеләр һәм учреждениеләр**
**ИСЕМЛЕГЕ**

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты-авыл җирлеген төзекләндерү буенча төрле эш башкаручылар.

**Печищи авыл җирлеге Башлыгы Л.В.Яковлев**